ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КИЛЬДЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КИЛДИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                КАРАР

17.04.2017                с. Кильдеево                11

«Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» проектны әзерләү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8, 33 статьялары, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2017 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә,

карар бирәм:

1. «Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләүгә керешергә.

2. «Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү комиссиясен төзергә, аның составын 1 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Шәһәр төзелешен зоналаштыру этапларын 3 нче кушымта нигезендә билгеләргә.

5. «Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү эшләрен башкару тәртибен һәм срокларын 4 нче кушымта нигезендә билгеләргә.

5. Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү буенча кызыксынучы затларның тәкъдимнәрен комиссиягә җибәрү тәртибен 5 нче кушымта нигезендә билгеләргә.

6. “Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында” Килди авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 04 апрелендәге 16 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

7. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук Килди авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге башлыгы В. М. Бурдин

Югары Ослан муниципаль
районының Килди авыл җирлеге
башкарма комитетының
2017 елның 17 апреленнән
№ 11 карарына
1 нче кушымта

«Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү комиссиясе турында нигезләмә

| | |
|---|---|
| Бурдин Виктор Михайлович | Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге башлыгы, комиссия рәисе |
| Минһаҗев Зәкиулла Зыятдин улы | Югары Ослан муниципаль районы Башлыгының архитектура һәм төзелеш мәсьәләләре буенча киңәшчесе, комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Лёвочкина Наталья Николаевна | Килди авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре, комиссия секретаре |
| Кобзева Екатерина Витальевна | Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Потапова Любовь Петровна | Югары Ослан муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча) |

Югары Ослан муниципаль
районының Килди авыл җирлеге
башкарма комитетының
2017 елның 17 апреленнән № 11
карарына

2нче кушымта

«Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү комиссиясе турында нигезләмә

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

Югары Ослан муниципаль районының «Килди авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җирдән файдалануны һәм төзелешне җайга салу системасының эзлекле камилләшүен һәм нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү өчен (алга таба - Җирлек) Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү комиссиясе (алга таба - Комиссия) төзелә.

Комиссия Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге башкарма комитеты карары нигезендә төзелә.

Комиссия даими эшләүче булып тора һәм Килди авыл җирлеге Советы карары кабул ителгәнчегә кадәр «Югары Ослан муниципаль районының «Килди авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карары кабул ителгәнчегә кадәр әлеге Нигезләмә нигезендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра.

## 2. КОМИССИЯ СОСТАВЫ

2.1. Комиссия составы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Башкарма комитеты карары белән раслана.

2.2. Комиссия рәисе булмаганда, аның вазифаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

## 3. КОМИССИЯ КОМПЕТЕНЦИЯСЕ

3.1. Комиссия компетенциясенә керә:

3.1. Җирдән файдалануны һәм төзелешне җайга салу системасын эзлекле камилләштерү процессын оештыру, шул исәптән җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр проектын эшләүне, ә алга таба аларны гамәлгә ашыру;

3.2. «Килди авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җир куллану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр проектын эшләүгә бәйле рәвештә гражданнарның һәм юридик затларның тәкъдимнәрен карау;

3.3. Югары Ослан муниципаль районының «Килди авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр проекты буенча гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү;

3.4. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә бирү, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә Югары Ослан муниципаль районының Килди

авыл җирлеге башлыгына тәкъдимнәр әзерләү һәм җибәрү.

## 4. КОМИССИЯ ЭШЧӘНЛЕГЕ ТӘРТИБЕ

4.1. Комиссия, кирәк булган саен, айга бер тапкырдан да ким булмаган күләмдә җыела.

4.2. Комиссия утырышы, Комиссия әгъзаларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала.

4.3. Комиссия карары Комиссия әгъзаларыннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, рәиснең тавышы хәлиткеч булып тора.

4.4. Гражданнарның һәм юридик затларның тәкъдимнәре Комиссия рәисе исеменә җибәрелә. Комиссия рәисе аларны комиссия утырышларында ике атна дәвамында карап тикшерүне тәэмин итә.

4.5. Күрсәтелгән тәкъдимнәрне карау нәтиҗәләре буенча беркетмәдә чагыла торган карар кабул ителә.

Югары Ослан муниципаль
районының Килди авыл җирлеге
башкарма комитетының
2017 елның 17 апреленнән № 11
карарына
3 нче кушымта

Җирлек территорияләренә карата шәһәр төзелеше зоналарының эзлеклелеге

1. Торак зоналары.
2. Иҗтимагый - эшлекле зоналар.
3. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге зоналар.
4. Рекреацион билгеләнештәге зоналар.

Махсус билгеләнештәге зоналар.

Югары Ослан муниципаль
районының Килди авыл җирлеге
башкарма комитетының
2017 елның 17 апреленнән № 11
карарына
4 нче кушымта

«Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җир куллану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү тәртибе һәм сроклары

| № т/б | Эшләрнең атамасы | Вакыт |
|---|---|---|
| 1 | Килди авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карар кабул итү турындагы хәбәрне бастырып чыгару | 2017 елның 19-21 апреле |
| 2 | Килди авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында комиссия тарафыннан проектны әзерләү | 2017 елның 22-27 апреле |
| 3 | Килди авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә комиссия тәкъдим иткән үзгәрешләр кертү турындагы проектны Килди авыл җирлегенең техник регламентлары таләпләренә, генераль планына туры килү-килмәүен тикшерү | 28 апрель 2017 ел |
| 4 | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектның техник регламентлар таләпләренә, Килди авыл җирлегенең генераль планына туры килүе яисә туры килмәве турында Килди авыл җирлеге башлыгы бәяләмәсен әзерләү | 28 апрель 2017 ел |
| 5 | Килди авыл җирлеге башлыгы тарафыннан җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында гавами тыңлаулар уздыру турында карар кабул итү | 2 нче май 2017 ел |
| 6 | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү, гавами тыңлаулар беркетмәләрен әзерләү, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында ачык тыңлаулар үткәрү | 13 май 13 июль 2017 ел |
| 7 | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә кушымталар белән гавами тыңлаулар тәмамланганнан соң үзгәрешләр кертү турында проект Килди авыл җирлеге башлыгына тәкъдим итү: гавами тыңлаулар беркетмәләре, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә | 2017 елның 14-20 июле |
| 8 | Килди авыл җирлеге башлыгының Килди авыл җирлеге Советына җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проектны җибәрү турында Карар кабул итү. | 2017 елның 20-21июле |

Югары Ослан муниципаль
районының Килди авыл җирлеге
башкарма комитетының
2017 елның 17 апреленнән № 11
карарына
5 нче кушымта

«Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында кызыксынган затларның тәкъдимнәрен комиссиягә җибәрү тәртибе

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Башкарма комитетының «Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге «муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект әзерләү хакында» карары басылып чыкканнан соң (алга таба - Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү турында проект), кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү турындагы проектны әзерләү буенча эшләрне үткәрү вакыты дәвамында кызыксынган затлар җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект әзерләү комиссиясенә (алга таба - Комиссия) кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү буенча тәкъдимнәр җибәрергә хокуклы.

2. Тәкъдимнәрне почта аша яки турыдан туры комиссиягә (“Җирдән куллану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проектны әзерләү комиссиясенә” тамгасы белән) түбәндәге адрес буенча җибәрергә мөмкин: 422585, ТР, Югары Ослан муниципаль районы, Килди авылы, Үзәк ур., 16 йорт, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге башкарма комитеты. Контакт телефоннары 8(84379) 34-7-41.

3. Тәкъдимнәр, аның тулы фамилиясен, исемен, атасының исемен, тәкъдимнәрне әзерләү урынының адресын күрсәтеп, бәян иткән зат имзасы белән язма рәвештә (бастырып чыгарылган яисә аңлаешлы итеп язылган) бәян ителергә тиеш. Төгәл язылмаган, имзаланмаган тәкъдимнәр, шулай ук Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү турындагы проектны әзерләүгә катнашы булмаган тәкъдимнәр комиссия тарафыннан каралмый.

4. Тәкъдимнәрдә теләсә нинди материаллар (кәгазьдә дә, шулай ук магнит чыганакларында) булырга мөмкин. Җибәрелгән материаллар кире кайтарылырга тиеш түгел.

5. Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү эшләре тәмамланганнан соң комиссиягә кергән тәкъдимнәр каралмый.

6. Комиссия кергән тәкъдимнәргә җавап бирми.